БАЛТАСИНСКИЙ
РАЙОННЫЙ СОВЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Ленина, д. 42, п.г.т. Балтаси, 422250

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН СОВЕТЫ
Ленин ур., 42 нче йорт, ш.т.п. Балтач, 422250

Тел.: (84368) 2-41-85, факс: (84368) 2-44-50. E-mail: Baltasi.Sovet@tatar.ru, www.baltasi.tatarstan.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

17 декабрь 2019 ел № 225

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының муниципаль мөлкәт Исемлегенә кертелгән, өченче затлар хокукыннан азат булган (хуҗалык алып бару хокукыннан, оператив идарә хокукыннан, шулай ук кече һәм урта эшкуарлык субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш) кече һәм урта эшкуарлык субъектларына, кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга биләүгә һәм (яки) файдалануга тапшыру өчен билгеләнгән муниципаль мөлкәтен, шул исәптән җир кишәрлекләрен (шәхси ярдәмче хуҗалык, яшелчәчелек, бакчачылык, шәхси торак төзелеше алып бару өчен билгеләнгән җир кишәрлекләреннән тыш) арендага бирү Тәртибен һәм муниципаль мөлкәтне формалаштыру, алып бару һәм бастырып чыгару Тәртибен раслау турында**

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә кече һәм урта эшкуарлык субъектларына, кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм инфраструктурасын төзүче оешмаларга мөлкәти ярдәм күрсәтү максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясына, «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Балтач район Советы **карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының муниципаль мөлкәт Исемлегенә кертелгән, өченче затлар хокукыннан азат булган (хуҗалык алып бару хокукыннан, оператив идарә хокукыннан, шулай ук кече һәм урта эшкуарлык субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш) кече һәм урта эшкуарлык субъектларына, кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга биләүгә һәм (яки) файдалануга тапшыру өчен билгеләнгән муниципаль мөлкәтен, шул исәптән җир кишәрлекләрен (шәхси ярдәмче хуҗалык, яшелчәчелек, бакчачылык, шәхси торак төзелеше алып бару өчен билгеләнгән җир кишәрлекләреннән тыш) арендага бирү Тәртибен расларга (1 нче кушымта).

2. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының муниципаль мөлкәт Исемлегенә кертелгән, өченче затлар хокукыннан азат булган (хуҗалык алып бару хокукыннан, оператив идарә хокукыннан, шулай ук кече һәм урта эшкуарлык субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш) кече һәм урта эшкуарлык субъектларына, кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга биләүгә һәм (яки) файдалануга тапшыру өчен билгеләнгән муниципаль мөлкәтен, шул исәптән җир

кишәрлекләрен (шәхси ярдәмче хуҗалык, яшелчәчелек, бакчачылык, шәхси торак төзелеше алып бару өчен билгеләнгән җир кишәрлекләреннән тыш) Исемлеген формалаштыру, алып бару һәм бастырып чыгару Тәртибен расларга (2 нче кушымта).

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматның рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм Балтач муниципаль районының рәсми сайтында http://baltasi.tatarstan.ru урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Балтач муниципаль районының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы рәисе И.М. Фәтхетдиновка йөкләргә.

Балтач муниципаль район башлыгы,
Балтач район Советы рәисе Р. Р. Нотфуллин

Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы Советының
2019 елның 17 декабрендәге
225 номерлы карарына
1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының муниципаль мөлкәт Исемлегенә кертелгән, өченче затлар хокукыннан азат булган (хуҗалык алып бару хокукыннан, оператив идарә хокукыннан, шулай ук кече һәм урта эшкуарлык субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш) кече һәм урта эшкуарлык субъектларына һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга биләүгә һәм (яки) файдалануга тапшыру өчен билгеләнгән муниципаль мөлкәтен, шул исәптән җир кишәрлекләрен (шәхси ярдәмче хуҗалык, яшелчәчелек, бакчачылык, шәхси торак төзелеше алып бару өчен билгеләнгән җир кишәрлекләреннән тыш) арендага бирү Тәртибе**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының муниципаль мөлкәт Исемлегенә кертелгән, өченче затлар хокукыннан азат булган (хуҗалык алып бару хокукыннан, оператив идарә хокукыннан, шулай ук кече һәм урта эшкуарлык субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш) кече һәм урта эшкуарлык субъектларына, кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга биләүгә һәм (яки) файдалануга тапшыру өчен билгеләнгән муниципаль мөлкәтен, шул исәптән җир кишәрлекләрен (шәхси ярдәмче хуҗалык, яшелчәчелек, бакчачылык, шәхси торак төзелеше алып бару өчен билгеләнгән җир кишәрлекләреннән тыш) арендага бирү Тәртибе (алга таба - Тәртип) Россия Федерациясе Граждан кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль закон, «Конкуренцияне яклау турында» 2006 елның 26 июлендәге 135-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының муниципаль хокукый актлары нигезендә эшләнде.

1.2. Исемлеккә кертелгән мөлкәтнең милекчесе булып Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль берәмлеге тора.

1.3. Исемлекне формалаштыру, алып бару, мәҗбүри бастырып чыгару Тәртибе Татарстан Республикасы Балтач муниципаль район Советы карары белән билгеләнә.

1.4. Тәртип Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының муниципаль мөлкәт Исемлегенә кертелгән, өченче затлар хокукыннан азат булган (хуҗалык алып бару хокукыннан, оператив идарә хокукыннан, шулай ук кече һәм урта эшкуарлык субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш), кече һәм урта эшкуарлык субъектларына, кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга биләүгә һәм (яки) файдалануга бирү өчен билгеләнгән муниципаль мөлкәтен, шул исәптән җир кишәрлекләрен (шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, яшелчәчелек, бакчачылык, шәхси торак

төзелеше өчен билгеләнгән җир кишәрлекләреннән тыш) арендага бирү процедурасын (алга таба - Исемлек) һәм мондый мөлкәтне кече һәм урта эшкуарлык субъектларына аренда түләвенең ташламалы ставкалары буенча арендага бирү шартларын билгели.

1.5. Муниципаль мөлкәтне арендага бирүче булып Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль милекчесенең вәкаләтләрен тормышка ашырырга вәкаләтле орган - Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы тора.

1.6. Аренда түләвенең ташламалы ставкаларында исемлеккә кертелгән мөлкәтне арендалаучылар булып «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә ярдәм күрсәтелә алмый торган кече һәм урта эшкуарлык субъектларыннан кала, кече һәм урта эшкуарлык субъектлары тора.

## II. Муниципаль мөлкәтне арендага бирү

2.1. Исемлеккә кертелгән мөлкәтне арендалау шартнамәләре төзү исемлеккә кертелгән мөлкәтне арендалау шартнамәләре төзү хокукына аукцион формасында ачык сату нәтиҗәләре буенча башкарыла (алга таба - сатулар).

2.2. Арендага бирүче сатуларны оештыру һәм үткәрү функцияләрен башкара.

2.3. Сатуларны үткәрү, исемлеккә кертелгән мөлкәтне арендалау шартнамәләрен төзү сатуларны үткәрү нәтиҗәләре буенча гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

2.4. Кече һәм урта эшкуарлык субъектлары тарафыннан сатуларда катнашуга гаризалар бирү, гаризага кушып бирелә торган документларга таләпләр, сатуларда катнашудан баш тарту өчен нигезләр аукцион турындагы документлар белән билгеләнә.

2.5. Исемлеккә кертелгән муниципаль мөлкәтне арендалаучы аренда түләвенең ташламалы ставкалары буенча төзелгән аренда шартнамәсе буенча үз хокукларын һәм бурычларын, өченче затларга тапшырырга, шул исәптән субаренда шартнамәләрен төзергә, мөлкәткә хокукны читләштерергә, арендаторга муниципаль мөлкәтне арендалау килешмәсе буенча бирелгән мөлкәт хокукын йөкләү нәтиҗәсе булырлык гамәлләр башкарырга хокуклы түгел.

2.6. Арендалаучы муниципаль мөлкәтне «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән тыюларны үтәү шарты белән бары тик максатчан билгеләнеше буенча гына файдаланырга тиеш.

2.7. Исемлеккә кертелгән мөлкәткә карата шартнамәләр төзелә торган вакыт кимендә биш ел булырга тиеш. Шартнамәнең вакыты, мондый шартнамә төзелгәнче, биләү һәм (яки) файдалану хокукын алучы затның гаризасы нигезендә киметелергә мөмкин.

## III. Аренда түләве һәм аны кертү тәртибе

3.1. Исемлеккә кертелгән мөлкәтне арендалау шартнамәләре өчен муниципаль мөлкәтнең аренда түләве күләме сатулар үткәрү нәтиҗәләре буенча билгеләнә.

3.2. Аренда шартнамәсе башлангыч бәясе бәяләү эшчәнлеге турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә әзерләнгән аренда түләвенең базар

бәясен бәяләү турындагы хисап нигезендә билгеләнә.

3.3. Исемлеккә кертелгән мөлкәтне арендалау шартнамәсе төзегәндә, биш ел вакытка арендалаучы тарафыннан түләү түбәндәгечә кертелә:

- аренданың беренче елында - аренда шартнамәсендә билгеләнгән аренда түләве күләменең 0 проценты;

- аренданың икенче елында - аренда шартнамәсендә билгеләнгән аренда түләве күләменең 0 проценты;

- аренданың өченче елында - аренда шартнамәсендә билгеләнгән аренда түләве күләменең 25 проценты;

- аренданың дүртенче елында - аренда шартнамәсендә билгеләнгән аренда түләве күләменең 50 проценты;

- аренданың бишенче елында һәм алга таба - аренда шартнамәсендә билгеләнгән аренда түләве күләменең 75 проценты.

3.4. Исемлеккә кертелгән мөлкәтне арендалау шартнамәсе төзегәндә яңа срокка арендалаучы тарафыннан 100 процент күләмендә аренда түләве кертелә.

3.5. Шартнамәне вакытыннан алда өзгән очракта, арендалаучыга, сатуларны үткәрү нәтиҗәләре буенча билгеләнгән базар бәясеннән чыгып, мөлкәт белән файдалануның бөтен вакыты буенча тулысынча түләргә кирәк була.

3.6. Муниципаль мөлкәтне файдаланган өчен аренда түләве Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы бюджетына күчерелә.

## IV. Якларның җаваплылыгы

4.1. Шартнамәдә каралган йөкләмәләрне үтәмәгән яки тиешенчә үтәмәгән өчен арендага бирүче һәм арендалаучы Россия Федерациясе законнары (Россия Федерациясе Граждан кодексы нигезендә мондый үтәлмәгән яки тиешенчә үтәлмәгән зыяннарны каплау бурычын да кертеп) һәм шартнамә нигезендә җаваплы.

4.2. Көтелмәгән (форс-мажор) хәлләр килеп туган очракта, яклар Россия Федерациясе законнары нигезендә шартнамә буенча йөкләмәләрдән азат ителә.

## V. Шартнамәне вакытыннан алда өзү тәртибе

5.1. Россия Федерациясе граждан законнарында каралган тәртиптә, шулай ук арендалаучы аренда шартнамәсе төзелгән көннән алып ике ел дәвамында исемлеккә кертелгән аренда мөлкәтен максатчан билгеләнеше буенча куллана башламаган булса, шартнамә вакытыннан алда өзелергә мөмкин.

Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль район Советының
2019 елның 17 декабрендәге
225 номерлы карарына
2 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының муниципаль мөлкәт Исемлегенә кертелгән, өченче затлар хокукыннан азат булган (хуҗалык алып бару хокукыннан, оператив идарә хокукыннан, шулай ук кече һәм урта эшкуарлык субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш) кече һәм урта эшкуарлык субъектларына, кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга биләүгә һәм (яки) файдалануга тапшыру өчен билгеләнгән муниципаль мөлкәте, шул исәптән җир кишәрлекләре (шәхси ярдәмче хуҗалык, яшелчәчелек, бакчачылык, шәхси торак төзелеше алып бару өчен билгеләнгән җир кишәрлекләреннән тыш) Исемлеген формалаштыру, алып бару һәм бастырып чыгару Тәртибе**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының муниципаль мөлкәт Исемлегенә кертелгән, өченче затлар хокукыннан азат булган (хуҗалык алып бару хокукыннан, оператив идарә хокукыннан, шулай ук кече һәм урта эшкуарлык субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш), кече һәм урта эшкуарлык субъектларына, «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә мөлкәти ярдәм күрсәтү максатларында, биләүгә һәм (яки) озак вакытлы түләүле файдалануга, шул исәптән ташламалы шартларда да, бирү өчен билгеләнгән муниципаль мөлкәте, шул исәптән җир кишәрлекләре (шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, яшелчәчелек, бакчачылык, шәхси торак төзелеше өчен билгеләнгән җир кишәрлекләреннән тыш) исемлеген (алга таба - Исемлек) формалаштыру, алып бару һәм бастырып чыгару ысулын билгели.

1.2. Исемлекне формалаштыруны Балтач муниципаль районының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы гамәлгә ашыра.

## 2. Исемлекне формалаштыру тәртибе

2.1. Исемлек әлеге Тәртипнең 2.2 пунктында күрсәтелгән, өченче затларның башка хокукларыннан (хуҗалык алып бару хокукыннан, оператив идарә хокукыннан тыш) азат булган, шулай ук Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы казнасы мөлкәте булган муниципаль мөлкәттән төзелә.

2.2. Кече һәм урта эшкуарлык субъекты тарафыннан арендалана торган мөлкәт Исемлегенә кертелгәндә, арендалана торган мөлкәтне милеккә сатып алуга өстенлекле хокукны гамәлгә ашыру тәртибенә карата «Дәүләт яисә муниципаль милектәге, кече һәм урта эшкуарлык субъектлары арендалый торган күчемсез мөлкәтне читләштерү үзенчәлекләре турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2008 елның 22 июлендәге 159 номерлы Федераль закон (алга таба - 159-ФЗ номерлы Закон) нигезләмәләре турында, шулай ук Исемлеккә кертелгән мөлкәтне арендалаучы кече һәм урта

эшкуарлык субъектларына ташламалар турында мәгълүматы булган, тиешле тәкъдимне җибәрү юлы белән мөлкәтне исемлеккә кертүгә арендалаучының язма ризалыгын алырга кирәк.

2.3. Арендага бирелгән мөлкәтне Исемлектән төшереп калдыру турындагы карар, мөлкәтне исемлектән төшереп калдыру аның бетүе яки юк ителүе, шулай ук арендалаучы тарафыннан № 159-ФЗ Закон нигезендә мөлкәтне сатып алу кебек хәлләргә бәйле очраклардан тыш, арендалаучының язма ризалыгы булганда кабул ителә.

2.4. Исемлеккә мөлкәт турында түбәндәге критерийларга туры килә торган мәгълүматлар кертелә:

1) мөлкәт өченче затларның хокукларыннан ирекле (хуҗалык алып бару хокукыннан, оператив идарә хокукыннан, шулай ук кече һәм урта эшкуарлык субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш);

2) федераль законнар мөлкәтенә карата аны вакытлыча хуҗа булуга һәм (яки) файдалануга, шул исәптән арендага бирүгә тыю билгеләнмәгән;

3) мөлкәт дини билгеләнештәге объект булып тормый;

4) мөлкәт капиталь ремонт яисә реконструкция үткәрүне таләп итми, төзелеп бетмәгән объект булып тормый, җирле үзидарә органының норматив хокукый акты белән капиталь ремонт, реконструкция, төзелеш эшләрен төгәлләүне таләп итә торган капиталь төзелеш объектларын арендага бирү җайга салынган очрактан тыш;

5) мөлкәт авария хәлендә һәм сүтелергә тиешле дип танылмаган;

6) мөлкәт торак фондына карамый һәм торак фонды объекты тоташтырылган инженер-техник тәэмин итү челтәре объекты булып тормый;

7) җир кишәрлеге шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, яшелчәчелек, бакчачылык, шәхси торак төзелеше өчен билгеләнмәгән;

8) кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына арендага бирелгән җир кишәрлекләреннән кала, җир кишәрлекләре Россия Федерациясе Җир кодексының 39.11 статьясындагы 8 пунктның 1-10, 13-15, 18 һәм 19 пунктчаларында каралган җир кишәрлекләренә карамый;

9) өч елдан кимрәк вакыт эчендә кече һәм урта эшкуарлык субъекты тарафыннан арендалана торган мөлкәткә карата арендалаучы вәкаләтле органның әлеге Тәртипнең 2.4 пунктында күрсәтелгән тәкъдименә җавап итеп Исемлеккә кертүгә каршылыклар җибәрмәгән;

10) мөлкәткә карата аренда шартнамәсе яисә башка гамәлдә булу вакыты кимендә биш ел булган шартнамә төзелгән.

2.5. Исемлеккә әлеге Тәртипнең 2.4 пунктында күрсәтелгән критерийларга туры килә торган түбәндәге мөлкәт кертелә:

1) күчемле мөлкәт: исемлеккә кертү датасына хезмәт итү вакыты биш елдан артмаган, икътисади характеристикалар һәм мораль тузуны исәпкә алып, файдаланырга яраклы җиһазлар, машиналар, механизмнар, җайланмалар, инвентарь;

2) инженер-техник тәэмин итү челтәрләренә тоташтырылган яисә тоташтырырга мөмкин булган һәм транспорт инфраструктурасы объектларына керә ала торган күчемсез мөлкәт объектлары;

3) торак пунктлар чикләрендә булган административ, сәүдә, җитештерү яки офис максатлары өчен файдаланырга планлаштырылган күчемсез мөлкәт объектлары;

2.6. Мөлкәтне исемлектән төшереп калдыру түбәндәге очракларда башкарыла:

1) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә мөлкәткә карата аны муниципаль ихтыяҗлар өчен куллану турында карар кабул ителгәндә. Мөлкәтне Исемлектән төшереп калдыру турындагы карарда мөлкәтне файдалану юнәлеше һәм тиешле карарның реквизитлары күрсәтелә;

2) муниципаль мөлкәт хокукы суд карары буенча яисә законда билгеләнгән башка тәртиптә туктатылганда;

3) бетүе яки юк ителүе нәтиҗәсендә мөлкәт гамәлдән чыкканда;

4) мөлкәтнең Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә физик яки мораль яктан тузуы, авария хәленә килүе нәтиҗәсендә файдалану өчен яраксыз дип танылганда;

5) нәтиҗәдә мөлкәт үз билгеләнеше буенча файдалану өчен яраксызга әверелә торган әлеге мөлкәтнең сан һәм сыйфат характеристикаларын үзгәрткәндә;

6) муниципаль мөлкәтне арендалау шартнамәсен төзү хокукына өч тапкыр аукционнар (конкурслар) үткәргәндә, аларны үткәрү нәтиҗәләре буенча гамәлдәге законнар нигезендә аренда шартнамәләре төзелмәгәндә. Әлеге мөлкәткә карата аны алга таба файдалану буенча идарә карары кабул ителә;

7) күрсәтелгән максатларда объектны (мөлкәтне) файдалануның максатка ярашсызлыгы.

2.7. Мөлкәт Исемлеге Балтач муниципаль районы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре Палатасы карары белән раслана.

## 3. Исемлекне алып бару тәртибе

3.1. Исемлекне алып бару Балтач муниципаль районының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы тарафыннан кәгазь һәм электрон чыганакларда алып барыла.

3.2. Исемлек түбәндәге белешмәләрне үз эченә алган реестрдан гыйбарәт:

- тәртип буенча номер;
- мөлкәтнең реестр номеры;
- муниципаль күчемсез мөлкәтнең урнашу урыны;
- күчемсез мөлкәт объекты төре;
- мөлкәтнең идентификацион белешмәләре (кадастр номеры һ. б.);
- мөлкәт характеристикасы (мәйданы, катлары, озынлыгы һ. б.);
- муниципаль мөлкәтнең атамасы;
- мөлкәтнең хокуклы иясе;
- мөлкәткә карата чикләүләр (йөкләүләр) турында мәгълүмат.

## 4. Исемлекне бастырып чыгару тәртибе

4.1. Исемлек һәм аңа кертелә торган үзгәрешләр Балтач муниципаль районының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы тарафыннан «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм Балтач муниципаль районының рәсми сайтында http://baltasi.tatarstan.ru, массакүләм мәгълүмат чараларында расланган көннән алып 10 эш көненнән дә соңга калмыйча һәм аңа үзгәрешләр кертелгән көннән соң 10 эш көненнән дә соңга калмыйча мәҗбүри басылып чыгарга тиеш.